СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2026 елның 13 апреле** Бишнә авылы **№ 33**

Бишнә авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Бишнә авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында гы» 2008 елның 10 ноябрендәге 118 номерлы карары;
- «Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы»2010 елның 10 мартындагы 163 номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 гыйнварындагы 98 номерлы карары белән расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы» 2017 елның 07 июлендэге №115 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**